# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба - Вәкаләтле вәкил) кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең дәүләт тарафыннан яклану гарантияләрен көчәйтү, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, урындагы затлар тарафыннан аларның үтәлүенә һәм хөрмәт ителүенә булышлык күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә сайлана.

Әлеге Законда күрсәтелгән чаралар ярдәмендә Вәкаләтле вәкил суд һәм яклауның башка юллары белән бозылган хокукларны торгызуга, Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, аларны яклау рәвешләре һәм ысуллары мәсьәләләре буенча хокукый белем бирүгә ярдәм итә.

<u>2 статья.</u> Вәкаләтле вәкил әлеге Законда билгеләнгән компетенция чикләрендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда бәйсез була.

3 статья. Вәкаләтле вәкилнең хезмәт урыны дәүләт хезмәт урыны була һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәт урыннары реестрына кертелә.

Үз эшчәнлегендә Вәкаләтле вәкил гомумтанылган халыкара хокук нормаларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, әлеге Законга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы катнаша торган халыкара шартнамәләргә, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив-хокукый актларга таяна.

4 статья. Татарстан Республикасы территориясендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылган очракта, аларны яклау Вәкаләтле вәкил компетенциясенә керә.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауның моңа кадәр булган чараларын тулыландыра, бозылган хокукларны һәм ирекләрне яклауны тәэмин итүче дәүләт органнары компентенцияләрен юкка чыгармый һәм аларны яңадан карауга китерми.

5 статья. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләр чоры - биш ел. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре яңа Вәкаләтле вәкил сайланган мизгелдән туктатыла.

Вәкаләтле вәкил, ант итү мизгеленнән башлап, үз вазыйфаларына керешкән, дип санала. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре чоры узу Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре туктатылуга китерми.

Бер үк зат рәттән ике тапкырдан да күбрәк чорга Вәкаләтле вәкил урынына сайлана алмый.

0379

## II бүлек. Вәкаләтле вәкилне сайлау һәм аны урыныннан азат итү тәртибе

6 статья. Татарстан Республикасы гражданы булган, 35 яше тулган, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә белемнәргә, аларны яклау тәҗрибәсенә ия булган зат Вәкаләтле вәкил итеп сайлана.

7 статья. Вәкаләтле вәкил урынына кандидатлар турында тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кертелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Вәкаләтле вәкил сайлауны элеккеге Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләр чоры бетү көненә кадәр ике айдан да соңга калмыйча үткәрә.

8 статья. Вәкаләтле вәкил хезмәт урынына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының билгеләнгән санлы составыннан күпчелек тавыш белән ачык яисә яшерен тавыш биреп сайлана.

9 статья. Үз вазыйфасына керешкәндә Вәкаләтле вәкил түбәндәге эчтәлектә ант итә: «Татарстан Республикасына тугрылыклы булырга, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен якларга, Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил буларак үземә йөкләнгән югары бурычларны намус белән үтәргә тантаналы рәвештә сүз бирәм».

Ант итү Вәкаләтле вәкил үз урынына сайланганнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында башкарыла.

10 статья. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы халык депутаты, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты була алмый, мөгаллимлек, фәнни йә бүтән иҗади эшчәнлектән тыш, түләүле һәм түләүсез башка эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый.

Вәкаләтле вәкил сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнергә, сәяси партия яисә сәяси максатлар куючы иҗтимагый берләшмә әгъзасы булырга хокуклы түгел.

Вәкаләтле вәкил, вазыйфаларын башкаруга керешкәннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча, үз статусына туры килми торган эшчәнлекне туктатырга тиеш. Вәкаләтле вәкил куелган таләпләрне билгеләнгән вакыт эчендә үтәмәсә, аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яңа Вәкаләтле вәкил сайлый.

11 статья. Татарстан Республикасы территориясендә Вәкаләтле вәкил суд тәртибендә салына торган административ җаваплылыкка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгыннан башка тартыла алмый.

12 статья. Вәкаләтле вәкил түбәндәге очракларда хезмәт урыныннан вакытыннан алда азат ителә:

а) Вәкаләтле вәкилгә карата судның гаепләү карары закон көченә кергәндә;

б) әлеге Законның 9 статьясы таләпләре бозылганда.

Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре Дәүләт Советы тарафыннан аның озак вакыт авыруы яисә бүтән сәбәпләр аркасында үз вазыйфаларын башкарырга сәләтсезлеге (тоташтан кимендә дүрт ай) аркасында да туктатылырга мөмкин.

Вәкаләтле вәкил үз вәкаләтләрен туктату турында гариза биргән очракта да хезмәт урыныннан азат ителергә мөмкин.

Вәкаләтле вәкилне вакытыннан алда хезмәт урыныннан азат итүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының билгеләнгән санлы составыннан күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы башкара.

13 статья. Вәкаләтле вәкил вакытыннан алда хезмәт урыныннан азат ителгәндә, яңа Вәкаләтле вәкил элеккеге Вәкаләтле вәкил вакытыннан алда хезмәт урыныннан азат ителгән көннән ике ай эчендә әлеге Законның 6-8 статьяларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланырга тиеш.

III бүлек. Вәкаләтле вәкилнең компетенциясе

14 статья. Үзенең төп бурычларын үтәү максатларында Вәкаләтле вәкил:

- кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт органнарыннан алына торган, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу мәсьәләләре буенча гражданнарның һәм иҗтимагый оешмаларның мөрәҗәгатьләреннән, әлеге мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләреннән алына торган мәгълүматны җыя һәм анализлый;

- дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, урындагы затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Татарстан Республикасы гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыксыз затларның шикаятьләрен карый, ул моны мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасында хокукый яклауның барлык чараларын кулланганнан соң гына башкара;

- кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлеше турында ел саен хәбәр әзерли һәм, календарь елы тәмамлангач өч

айдан да соңга калмыйча, аларны Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрә. Вәкаләтле вәкил кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына махсус хәбәрләр җибәрергә мөмкин. Вәкаләтле вәкилнең еллык хәбәрләре «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында басылып чыга, махсус хәбәрләре Вәкаләтле вәкил карары буенча басылып чыгарга мөмкин;

- кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы закон проектларын әзерләүдә катнаша.

15 статья. Вәкаләтле вәкил кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүгә һәм яклауга кагылышлы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

16 статья. Мөрәҗәгать итүче үзенең хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санаган көннән яисә хокук бозулар турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүм булган көннән бер елдан да соңга калмыйча шикаять язма рәвештә Вәкаләтле вәкилгә җибәрелә. Әгәр күрсәтелгән вакыт мөрәҗәгать итүчегә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында узып киткән булса, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең язма гаризасын хокук бозылган көннән соң бер ел узгач та алырга хокуклы.

Шикаятьтә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелергә, мөрәҗәгать итүче үзенең хокукларын һәм ирекләрен бозган яисә боза торган дип санаган гамәлләрнең (гамәл кылмауларның) яисә карарларның асылы бәян ителергә, шулай ук аның суд тәртибендә яисә административ тәртиптә каралган

шикаяте буенча кабул ителгән карарларның күчермәләре бирелергә тиеш.

Вәкаләтле вәкилгә җибәрелә торган шикаятькә дәүләт пошлинасы салынмый.

17 статья. Шикаятьне алганнан соң Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) шикаятьне карауга алырга;

2) мөрәҗәгать итүчегә үз хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен кулланырга хокукы булган чараларны аңлатырга;

3) шикаятьнең асылы буенча аны хәл итү кемнең компетенциясенә керүгә карап, шикаятьне дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә урындагы затка тапшырырга;

4) шикаятьне карауга алудан баш тартырга.

Кабул ителгән карар турында Вәкаләтле вәкил ун көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Шикаятьне карый башлаган очракта Вәкаләтле вәкил шулай ук карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә урындагы затка да хәбәр итә.

Шикаятьне карауга алудан баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш.

18 статья. Шикаятьне карарга керешкәч, Вәкаләтле вәкил ачыкланырга тиешле хәлләргә тикшерү уздыруда ярдәм сорап компетентлы дәүләт органнарына яисә урындагы затларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына, урындагы затка тикшерү йөкләнә алмый.

<u>19 статья.</u> Үзенең төп бурычларын гамәлгә ашыру максатларында Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте һәм идарәсенең барлык органнарына, җирле үзидарә органнарына тоткарлыксыз кереп йөрергә, аларның коллегиаль органнары утырышларында катнашырга, шулай ук, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә һәм хәрби частьларга тоткарлыксыз кереп йөрергә;

2) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, урындагы затлардан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән шикаятьне карау өчен кирәкле белешмәләр, документлар һәм материаллар сорарга һәм алырга;

3) шикаятьне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча, судьялардан гайре, урындагы затлардан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән аңлатмалар алырга;

4) дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм урындагы затларның кеше хокукларын бозулары турында Вәкаләтле вәкилдә мәгълүмат булган очракта, ул мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органы, урындагы затлар һәм дәүләт хезмәткәрләре белән берлектә аларның эшчәнлегенә тикшерү уздырырга;

5) дәүләт учреждениеләренә шикаятьне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча эксперт тикшеренүләре уздыруны һәм бәяләмәләр әзерләүне йөкләргә;

6) карарлары (хөкем карарлары) закон көченә кергән җинаять, граждан эшләре һәм административ хокук бозулар турындагы эшләр белән, шулай ук, җинаять эшләре кузгатылмыйча туктатылган эшләр һәм материаллар белән танышырга.

Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының,

оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның җитәкчеләре һәм урындагы бүтән затлары, иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкчеләре, хәрби формированиеләрнең башлыклар составындагы затлар, мәҗбүри тоту урыннарындагы администрация тарафыннан кичекмәстән кабул ителү хокукыннан файдалана.

20 статья. Дәүләт, коммерция серен йә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче мәгълүматны Вәкаләтле вәкилгә бирү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

21 статья. Шикаятьне караганда, Вәкаләтле вәкил гамәлләренә (гамәл кылмауларына) яисә карарларына карата шикаять белдерелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә урындагы затка тикшерү барышында ачыкланырга тиешле теләсә нинди мәсьәлә буенча үз аңлатмаларын бирү өчен, шулай ук тулаем үз позициясен дәлилләү өчен мөмкинлекләр бирергә тиеш.

Бирелгән аңлатмалар белән мөрәҗәгать итүчене таныштырырга мөмкин.

22 статья. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турында Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүчегә законнарда билгеләнгән вакытларда хәбәр итәргә тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең хокуклары бозылу факты билгеләнгән очракта Вәкаләтле вәкил үз компетенциясе чикләрендә чаралар күрергә тиеш.

23 статья. Карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу карала торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә урындагы затка Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән хокукларны һәм

ирекләрне торгызуның мөмкин булган һәм кирәкле чараларына карата рекомендацияләрне эченә алган үз бәяләмәсен җибәрергә тиеш.

24 статья. Хәлиткеч карар чыгарылганчы, шикаятьне караганда алынган материаллар фаш ителмәскә тиеш.

Шикаятьне карау барышында Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең һәм башка затларның шәхси тормышы турындагы белешмәләрне аларның язма ризалыгыннан башка фаш итә алмый.

25 статья. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт органының, җирле үзидарә органының яисә урындагы затның карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән бозылган хокукларны һәм ирекләрне яклап, гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә, шулай ук шәхсән үзе йә үзенең вәкиле аша законда билгеләнгән рәвешләрдә процесста катнашырга;

2) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозулары ачыкланган урындагы затларга карата дисциплинар яисә административ эш йә җинаять эше кузгату турындагы үтенечнамә белән компетентлы дәүләт органнарына мөрәҗәгать итәргә;

3) билгеләнгән тәртиптә закон көченә кергән суд карарын, хөкемен, суд билгеләмәсен яисә карарын йә судья карарын тикшерү турындагы үтенечнамә белән судка яисә прокуратурага мөрәҗәгать итәргә;

4) каршылык күрсәтергә хокукы булган, шулай ук эшне судта караганда күзәтүче буларак катнашырга хокукы булган урындагы затка үзенең дәлилләрен бәян итәргә;

5) конкрет эш буенча кулланылган яисә кулланылырга тиеш закон белән гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре

бозылу турында шикаять белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итәргә.

Әлеге статьяның беренче өлешендәге 3 пункты нигезендә Вәкаләтле вәкил тарафыннан җибәрелүче гаризага яисә шикаятькә дәүләт пошлинасы салынмый.

26 статья. Вәкаләтле вәкил үзе кабул иткән бәяләмәне матбугатта бастырып чыгарырга хокуклы.

Гамәлгә куючыларның берсе дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары булган йә Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган вакытлы матбугат басмасы Вәкаләтле вәкилнең бәяләмәләрен һәм башка төрле документларын бастырудан баш тартырга хокуклы түгел.

27 статья. Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу турындагы мәгълүматны өйрәнү һәм анализлау, шикаятьләрне карау йомгакларын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле зат түбәндәгеләргә хокуклы:

1) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүгә кагылышлы үзләренең искәрмәләрен һәм гомуми характердагы тәкъдимнәрен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм урындагы затларга җибәрергә;

2) Вәкаләтле вәкил, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының яисә урындагы затларның кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен боза торган карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмаулары) законнар һәм аларны үтәү нигезендә йә законнардагы җитешсезлекләр аркасында кылына, йә законнар халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына, Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләренә каршы килә дип санаганда, Вәкаләтле вәкилнең закон чыгару инициативасы

хокукын гамәлгә ашырып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына законнарга үзгәрешләр яисә өстәмәләр кертү турында закон проектлары кертергә.

<u>28 статья.</u> Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре тупас яисә массакүләм рәвештә бозылган очракта Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында нотык белән чыгыш ясарга хокуклы.

Вәкаләтле вәкил кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу фактларын тикшерү буенча парламент комиссиясе төзү турындагы һәм парламент тыңлаулары үткәрү турындагы тәкъдим белән Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук турыдан-туры үзе йә үзенең вәкиле аша күрсәтелгән комиссия эшендә һәм уздырыла торган парламент тыңлауларында катнашырга хокуклы.

<u>29 статья.</u> Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе дәүләт органнары тарафыннан кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылган очракта, Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясенең кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиленә, Татарстан Республикасы Президентына, хокук саклау органнарына, җәмәгать оешмаларына, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына мөрәҗәгать итә.

<u>30 статья.</u> Урындагы затлар Вәкаләтле вәкилгә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле соратып алынган материалларны һәм документларны, бүтән төрле мәгълүматны түләүсез һәм тоткарлыксыз бирергә тиеш.

Соратып алынган документлар, материаллар һәм бүтән төрле мәгълүмат Вәкаләтле вәкилгә, үтенечтә башка вакыт билгеләнмәгән булса, үтенеч алынганнан соң 15 көннән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

Вәкаләтле вәкилнең рекомендацияләре күрсәтелгән бәяләмәсен алган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә урындагы зат бер ай эчендә аларны карарга һәм күрелгән чаралар турында Вәкаләтле вәкилгә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

31 статья. Вәкаләтле вәкилнең карарына йогынты ясау максаты белән аның эшчәнлегенә тыкшыну, урындагы затларның әлеге Законда билгеләнгән үз вазыйфаларын үтәмәүләре, шулай ук Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә бүтән рәвешле каршылык күрсәтү законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

## IV бүлек. Вәкаләтле вәкил аппараты

32 статья. Вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты (алга таба - аппарат) булдырыла.

Аппарат Вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеген юридик, оештыру, фәнни-аналитик, мәгълүмати-белешмә һәм бүтән яктан тәэмин итә.

Вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты юридик зат хокукына ия дәүләт органы була, аның исәп-хисап һәм бүтән счетлары, үз исеме язылган һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән мөһере һәм бланклары була.

33 статья. Вәкаләтле вәкилнең һәм аның аппаратының эшчәнлекләрен финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле вәкилнең һәм аның аппаратының эшчәнлекләрен тәэмин итү өчен кирәкле акчалар Республика бюджетында ел саен аерым юл белән күрсәтелә.

Вәкаләтле вәкил үз чыгымнарының сметасын мөстәкыйль әзерли һәм башкара.

Вәкаләтле вәкил чыгымнар сметасы чикләрендә үз аппаратының санын һәм штат расписаниесен билгели.

Вәкаләтле вәкил финанс хисабын законнарда биеләнгән тәртиптә тапшыра.

Вәкаләтле вәкилгә һәм аның аппаратына үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәт аларның оператив идарәсендә тора һәм ул республика милке була.

34 статья. Вәкаләтле вәкил үзенең аппараты һәм аның структурасы турындагы нигезләмәне раслый һәм аның эшенә турыдан-туры җитәкчелек итә.

Вәкаләтле вәкил аппаратка җитәкчелек итүгә бәйле мәсьәләләр буенча боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара.

35 статья. Вәкаләтле вәкил аппараты хезмәткәрләре дәүләт хезмәткәрләре булалар.

Вәкаләтле вәкил аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, вазыйфалары һәм җаваплылыгы, шулай ук аларның дәүләт хезмәтендә эшләү шартлары дәүләт хезмәте турындагы закон һәм бүтән норматив хокукый актлар, шулай ук хезмәт турындагы законнар белән билгеләнә.

36 статья. Консультатив ярдәм күрсәтү максатларында Вәкаләтле вәкил каршында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә кирәкле белемгә ия булган затлардан эксперт советы төзелергә мөмкин.

## V бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

37 статья. Вәкаләтле вәкилнең даими урнашкан урыны - Казан шәһәре.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 3 марты
№ 95